ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең Коркачык ав. торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17 октябрь, 2022 ел № 4

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “2023 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең Коркачык ав. торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне:

1. Бөек Ватан сугышы һәйкәлен киртәләү буенча материаллар сатып алу һәм эшләү
2. Лампаларны сатып алу һәм урнаштыру.
3. Вак таш сатып алу , вак ташны жәю.
4. 2021 елның 30 ноябрендә халык җыены буенча җыелган үзара салым чараларына планлаштырылган эш төрләрен поселок эчендәге юлларны карап тоту өчен фронталь төягеч (трактор) сатып алу КДН-210 диск асылмалы һәм МТЗ-82 тракторы өчен коммуналь 1800 щеткасы үзгәртергә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

дигән сорау буенча 2022 елның 07 октябрендә 14 сәгать 00 минутта , 14 октябрендә 19 сәгать 00 митутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 506 (биш йөз алты) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 275 кеше, бу 54,30 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 275 (ике йөз житмеш биш) катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 (ноль) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге Коркачык ав. торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авылы җирлеге Коркачык ав. торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) суммада үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

1. Бөек Ватан сугышы һәйкәлен киртәләү буенча материаллар сатып алу һәм эшләү

2. Лампаларны сатып алу һәм урнаштыру.

3. Вак таш сатып алу , вак ташны жәю.

4. 2021 елның 30 ноябрендә халык җыены буенча җыелган үзара салым чараларына планлаштырылган эш төрләрен поселок эчендәге юлларны карап тоту өчен фронталь төягеч (трактор) сатып алу КДН-210 диск асылмалы һәм МТЗ-82 тракторы өчен коммуналь 1800 щеткасы үзгәртергә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Г.Р.Закирова